**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТЕЛӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

**КАРАР**
**уникенче утырыш**

**13 май 2022 ел** **№60** **Теләче ав.**

**Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 2021 елның 24 мартындагы 20 номерлы ««Теләче» сәнәгать паркы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советы карар итте,

1. Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 2021 елның 24 мартындагы 20 номерлы ««Теләче» сәнәгать паркы турында» карарына (30.07.2021 ел № 29, 10.03.2022 ел № 52 карарлар редакциясендә) үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 пунктны түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә: «1. 2022 елның 31 декабренә кадәр салым түләүдән азат итәргә: Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясен үстерү, икътисадның эшкәртү тармакларын үстерү, продукциянең яңа төрләрен җитештерү, иң прогрессив технологияләрне һәм җитештерүне гамәлгә кертү максатларында, Теләче муниципаль район Советы карары нигезендә төзелгән муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать парклары биләгән җир кишәрлекләренә яки Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары белән төзелгән индустриаль (сәнәгать) паркларына җир кишәрлеге милекчеләре тарафыннан җир кишәрлегенә резидентлар җәлеп ителгән очракта, башка очракларда җир салымыннан азат итү кулланылмый. Җир салымы буенча ташламаларны раслау өчен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән төзелгән муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать паркларының яки индустриаль (сәнәгать) паркларының идарә компаниясе, узган салым чорыннан соң килгән елның 1 июненнән дә соңга калмыйча, җир кишәрлекләре милекчеләренең исемлеген, ел дәвамында аларның җир кишәрлекләрендә эшчәнлек алып бару өчен резидентлар җәлеп иткән кадастр номерларын күрсәтеп, салым органына бирергә тиеш.».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль районы
Теләче авыл җирлеге башлыгы Н.Н. Хаҗипов